УДК 81’373.221

***И.И. Сабитова***

# ДОБРУҖА ТАТАРЛАРЫ ФОЛЬКЛОРЫНДА ФИТОНИМНАРНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

В данной статье анализируются особенности употребления и семантические характеристики фитонимов в текстах фольклорных произведений татар, проживающих в области Добруджа Румынии, и в татарском народном творчестве в сравнительном аспекте. Известное утверждение о том, что фитонимическая система языка отличается особой устойчивостью и сохраняется в языке на протяжении длительного времени, иначе говоря, консервативностью, находит свое подтверждение и на данном материале. Исследование сборника фольклорных текстов «Boztorgay» и сборника сказок «Ayuw kulak batır», показало общность большого пласта названия растений, т. е. наличие как полных, так и частичных соответствий в сравниваемых добруджататарском и татарском языках, а также значительное сходство многих семантических процессов. Анализ выявил какие смысловые оттенки названия растений приобретают в разных контекстах в сравниваемых языках, где они совпадают и чем отличаются. В этой статье мы стремимся на конкретных примерах показать сходство лексико-семантических процессов между сравниваемыми лексемами. Это сходство позволяет говорить об их общих корнях. Наблюдаемые различия, в первую очередь, объясняются результатом исторического развития фитонимической лексики добруджанских татар и татар Поволжья в различном языковом окружении и взаимодействии с различными контактирующими языками.

**Ключевые слова:** татарский язык, добруджататарский язык, диалект, фитоним, семантика, лексика, сравнение, параллельность

This article analyzes the peculiarities of the use and semantic characteristics of phytonyms in the texts of folklore works of the Dobrudzha Tatars and the Tatars of the Volga region in a comparative aspect. The well-known assertion that the phytonymic system of a language is characterized by particular stability and long-term preservation – i.e., conservatism – is confirmed by the material analyzed in this study. The study of the folklore collection Boztorgay and the fairy tale collection “Ayuw kulak batır” demonstrates the existence of a substantial shared layer of plant names, revealing both complete and partial correspondences between the Dobrujan Tatar and Volga Tatar languages, as well as a considerable similarity in many semantic processes. The analysis identifies the semantic nuances that plant names acquire in different contexts in the languages under comparison, highlighting both convergences and divergences. Through specific examples, the article aims to demonstrate the similarity of lexico-semantic processes observed in the compared lexemes. This similarity allows us to speak of their common roots. The differences identified are primarily explained by the historical development of phytonymic vocabulary among the Dobruja Tatars and the Volga Tatars in distinct linguistic environments and through interaction with different contact languages.

**Keywords:** Tatar language, Dobrudzhatatar language, dialect, phytonym, semantics, vocabulary, comparison, parallelism

Телнең фитонимик системасы борынгы заманнардан даими рәвештә үскән һәм катлауланган. Хәзерге вакытта ул – тулысынча формалашкан тотрыклы система. Әмма бу фитонимик лексика үсешенең тулысынча тукталуын аңлатмый. Телдә яңа сүзләр, яңа мәгънәләр барлыкка килү телнең даими үсештә булуын күрсәтә. Әлеге процесс фитонимик системага да хас. Сүзләрнең яңа вариантлары туа, семантик функцияләре киңәя, искеләре кулланыштан төшеп кала.

Татар тел белемендә фитонимнар шактый тирән өйрәнелгән. Аларның этимологиясен, тарихи-генетик катламнарын, номинацияләү принципларын, ясалыш калыпларын махсус тикшергән хезмәтләр бар [12; 4; 23; 2 һ. б.]. Диалектлардагы үсемлек атамалары Т.Х. Хәйретдинова тарафыннан җентекләп анализланган [24; 25]. Шул ук вакытта аерым текстлардагы үсемлек атамаларын чагыштырма планда өйрәнү дә актуальлеген югалтмый.

Соңгы елларда лингвистикада кырымтатар теленең бер диалекты булып исәпләнгән добруҗататар теле белән кызыксыну көчәйде [13; 14; 15]. Румыниянең Добруҗа төбәгендә яшәгән татарларның чыгышына, тарихына бәйле материалларны Г.А. Гусейнов, Т.Б. Усеинов һ. б. галимнәрнең хезмәтләрендә очратырга мөмкин [6; 7; 22; 28]. Авторлар фикеренчә, Добруҗа татарларының этник составын Кара диңгез буеннан гына түгел, Идел, Урал буйларыннан, хәтта Себердән килеп кушылган күпсанлы төрки телле төркемнәр барлыкка китергән. Күренекле тарихчы Җәмил Тахсин «Добруҗа татарларының телен генә түгел, гореф-гадәтләрен, фольклорын формалаштыруда Идел буе, ягъни Казан татарларының да өлеше бар», дип яза [28: 282–283]. Добруҗататар теле күпчелек тикшеренүчеләр тарафыннан кырымтатар теленең дала (төньяк, нугай) диалектына якын диалект дип карала.

Кырымтатар теле диалектларын тикшерүче Т.Б. Усенов «XIX–XX гасырлар чигендә дала Кырым татарлары ике эндоэтноним кулланган: «ногъайлар» һәм «татарлар». «Кырым татарлары» экзоэтнонимы халыкның үзатамасы буларак депортация чорында (1944 елдан соң) кулланыла башлый. Депортацияне кичермәгән Румыния татарлары исә, «Кырым татарлары» экзоэтнонимын кабул итмәгәннәр һәм бүген дә үзләрен «татарлар» дип атыйлар» [22: 41].

Бу мәкаләдә фольклор әсәрләре текстларында фитонимнарның кулланылышы чагыштырма аспектта өйрәнелә. Тикшерү өчен күрсәтмәле материал тоташ сайлау методы белән Добруҗа татарлары авыз иҗатының төрле жанрларын колачлаган «Boztorgay» ‘Бозторгай – Тургай’ җыентыгыннан (нигездә, кыска җырлардан – манилардан) һәм «Ayuw kulak batır» ‘Аюв кулак батыр – Аюколак батыр’ әкиятләр җыентыгыннан тупланды [27; 26]. Татар теленнән иллюстратив материал фольклор җыентыкларыннан алынды, аерым очракларда сүзлекләргә мөрәҗәгать ителде.

Гомумтөрки катламга караган үсемлек атамаларының күбесе бүгенге көндә дә төрки телләрдә үзгәрешсез (шул ук фонетик тышчада

һәм семантикада яки фонетик варианты үзгәреп) кулланыла. Добруҗататар телендә дә алар күп сакланган. Борынгы төрки катламга караган *arpa ‘арпа’, biday ‘бодай’, tarı‘ тары’* (ашлык атамалары), *kaĭn ‘каен’, dal ‘тал’, çarşı ‘чыршы’, emen, meşe ‘имән’* (агач һәм куак атамалары), *kamış ‘камыш’, tegenek ‘тигәнәк’* (үлән үсемлекләре исемнәре), *pitak ‘ботак’, yaprak ‘яфрак’, kabık ‘кабык’, şıbık‘чыбык’, şeşek ‘чәчәк’, ot ‘үт’ «үлән», cemĭş ‘җимеш’, yüzüm ‘йөзем’, şetlewĭk ‘чикләвек’, tamır ‘тамыр’, tüb ‘төп’* (үсемлек анатомиясе белән бәйле лексик берәмлекләр), *sogan ‘суган’, sarımsak ‘сарымсак’, kawak ‘кабак’, kawun ‘кавын’, karbız ‘карбыз’* (яшелчәчелек белән бәйле үсемлек атамалары) һ. б. ларны күрсәтергә була. Төрле тематик төркемнәргә кергән әлеге атамалар фольклор әсәрләрендә аеруча еш очрый.

Кайбер тикшеренүчеләр *юкә* лексемасы татар теленең үз җирлегендә барлыкка килгән һәм бары татар телендә генә кулланыла дип раслый. Мәсәлән, Г.Г. Саберова «бу атама X–XII гасырларда татар халкы формалаша башлаган чорда барлыкка килгән һәм хәзерге вакытта ул башка төрки телләрдә очрамый», дип яза [11: 19]. Ләкин фольклор текстлары *yüke ‘юкә’* сүзенең добруҗататар телендә бүген дә киң кулланылышта булуын күрсәтә.

Фитолексика борынгы гына түгел, ә үтә тотрыклы төркемне тәшкил итә. Бу Добруҗа татарлары фольклоры текстларында ачык күренә. Генетик яктан борынгы төрки катламга караган фитонимнарның добруҗататар телендә һәм хәзерге татар телендә тулы һәм өлешчә параллельләре күп. Шулай ук бер атама урынына икенчесе кулланылган очраклар да бар.

Анализланган фитонимнар конкрет бер мәгънәгә ия. Шулай да тел үсеше барышында кайберләренең семантик функцияләре киңәя, төрле күчерелмә мәгънәләре арта бара. «Һәм нәкъ менә семантика күптөсле мәгънәләр палитрасына ия, ахыр чиктә ул телдә лексиканың валентлы, контекстуаль һәм башка функциональ мөмкинлекләрен куллануга сәбәп була» [15: 332]. Аерым үсемлек атамалары пассивлашып, тикшерелгән телләрнең берсендә әдәби телдә кулланыштан төшеп калып искергән сүзгә әйләнгән һәм, киресенчә, икенчеләре хәзерге вакытта да кулланышта.

*Агач* һәм *тирәк* атамаларының чагыштыра торган телләрдә кулланылышы кызыклы. Добруҗататар телендә *агач* сүзенең төп мәгънәсе – утын, коры агач, үзагач, материал: *Pırımcınıň agaşı, kasapşınıň pışagı yok eken; Onıň suwga batkan bĭr balası, bĭr agaşka sarılıp kurtulgan emĭş; Bĭr agaşnĭň tübĭne otırgan da gene cılamaga başlagan* [26: 210; 214; 239]. *Kart akay, er kün saba ormanga ketĭp, bĭr cük kurı agaş alıp kayta, son, olarnı pazarga aketĭp sata ... eken*; *Men barıp, taw ĭşĭnden tiyran agaş alıp kelgeşĭk, sen bolgan agaşnı cagıp, mınaw tontoloşnı aruw etĭp kaynat! die* ---; *Agaştan yasalgan kız canlangan da aynıň öndörtĭndiy güzel bĭr kız bolgan. Bĭr ay baltamız bar, ama agaş saplıdır* [26: 218; 197; 158; 151].

*Агач* атамасы татар әдәби телендә һәм аның сөйләшләрендә күптөрле мәгънәгә һәм мәгънә төсмерләренә ия. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә *агач* сүзенең беренче мәгънәсе биологик термин буларак «Төп сабагы каты кәүсә, ботаклары ябалдаш хасил иткән каты үзагачлы үсемлекләрнең гомуми атамасы» дип бирелә [16: 59]: *Агач башында асыл кош, Көш-көш дигән кеше юк.* [20: 49]. *Агач* лексемасының әлеге мәгънәсе добруҗататар авыз иҗатында очрамый диярлек: *Sıpa sıpa agaşlar Asker tâlĭmge başlar* [27: 150]. Бу мәгънәдә *тирәк* сүзе кулланыла: *Üy aldına otırttım 'Yeşersĭn' dep bır terek; Terek tolı kestane Şöpledĭm tâne tâne* [27: 158; 155].

Татар телендә *агач* атамасы еш кына сүзтезмәләр составында килеп, агачның төрен белдерә: *Карагай агач каен булмас, Каен гына суы бал булмас; Ишегалларымда бер тут агач, Күләгәсе төшә бакчага; Каен агачлары, әй, тал булмас, Каен суы әче бал булмас; Имән агачын кискәннәр Ак мәчеткә ишеккә; Тубылгы агач зур булмас, Тубылгы үтә юл булмас; Басмас та идем баскычың, Баскычларың бадъян агачы; Чия агачының очы Ничек нечкә була икән; Алма агачы, тал агачы Шаулый җилдә талганчы* [20: 42; 43; 44; 69; 78; 170; 282; 357]. Добруҗататар телендә исә мондый очраклар *terek* сүзе белән белдерелә: *May tereknĭn yprakları şuwdırdaşıp cerge tüşer*. [27: 36]. *Eskĭden, sencar, meşe tereklerĭnĭn kabıgın aşap keşĭne eken. Bĭr kün o cemĭş tolı findıknıñ teregĭne raslay*; *Ekĭncĭ künĭ sabası Köse --- kaynanasın uyanta, onı dut teregınĭñ üstĭne mĭnsete* --- [26: 245; 167].

Кырымтатарча-русча сүзлектә дә *ağaç* сүзе «1) древесина, деревянный; 2) *устар.* дерево см. *terek*», ә *terek* лексемасы «1) дерево – *terek oturtmaq*, *terek saçtaq* – сажать деревья» дип теркәлгән. *Кырым --- шефтали тереги, эрик тереги, чия-/-кираз тереги --- белән дан тота* [1: 17].

Татар теле сөйләшләрендә дә «агач» төшенчәсендә башка лексик берәмлекләр кулланыла. «Казан арты керәшеннәре, ләмбрә сөйләшләрендә *тирәк*, хвалын, мәләкәс, чистай сөйләшләрендә *тал* сүзләре күрсәтелгән мәгънәне белдерәләр» [25: 57]. Татар халкының этнотерриториаль төркеме булган Әстерхан татарлары да *агачның* «үсеп утыра торган үсемлек» мәгънәсендә *тирәк* сүзен кулланалар: *слива тирәге* [10: 45]. Диалекталь сүзлекләрдә дә *тирәк* атамасының төрле сөйләшләрдә төрле мәгънәләрдә кулланылуы күренә: «куак; куаклык; тармак; ботак; гөл; тополь; чигү бизәге; җирлек» [18: 634]. Бу төрки телләрнең территориаль аерымлануы белән аңлатыла.

*Тирәк* атамасының татар телендә семантик кыры киң. «Гомумән зур һәм биек агач»ны белдергән төп мәгънәсеннән тыш (*Сандугачлар талга төшә, Талдин тирәккә төшә* [20: 61]) аңлатмалы сүзлектә «тупыл; бизәк; туган нигез (байтирәк)» мәгънәсе дә күрсәтелгән [17: 578]: *Ак тарелка, зәңгәр тирәк, Эчләрендә май микән?!* [20: 207]. «Төрле тал агачлары; яфраклы талга охшаш биек агач» семантикасы түбәндәге очракта теркәлгән: *Бакчагызда тал-тирәк, Алмагачы бик сирәк; Су буенда тал-тирәкләр, Яннарында бадиян* [20: 230; 273].

Тал агачының синонимы буларак *тал тирәк, тал тирәге* фольклор әсәрләрендә сакланган: *Тал тирәкләре корыгач, Кошлар кунып сайрамый; Су буена төшкәнем юк, Үсә микән тал тирәк* [20: 56; 52]. Хәзерге вакытта бу сүзтезмә матур әдәбиятта гына очрый.

*Тал тирәк, тал тирәге* тезмәләренә охшаш конструкцияләр добруҗататар фольклорында *gülterek 'гөлтирәк', gül terek 'гөл тирәк'* төзелмәләре формасында очрый: *Bakşelerde gülterek Cel eskende sallana*; *Gül tereknĭñ dalı yok Bĭr yar süydüm malı yok*; *Üy aldında gül terek Baar kelse bürlensĭn* [27: 111; 126; 158].

Добруҗататар телендәге *süwüt terek* сүзе кырымтатар әдәби телендә *тупыл* һәм *кипарис* атамаларын белдергән *selbi* лексемасына туры килә: *Suw boyında aşlanır süwüt terek, Curtunda yaşap ölgen dünyada sirek* [27: 52]. Хәзерге татар әдәби телендә фарсы чыгышлы *сәрви* (сөйләм телендә *сәрби*) сүзе «акация»не белдерә. Дастаннарыбызда ул «кипарис» мәгънәсендә кулланылган: *Кил, и сәрви зифа назлым, Сиңа бик тилмерә җаным* [20: 172].

Төрле агачлар күп үскән урын мәгънәсен *tereklĭk 'тирәклек'* дериваты бирә: *Epĭsĭ de şoga razı bolıp, taw ĭşĭndekĭ bĭr tereklĭk arasına kĭşkene bĭr üy yapkanlar* --- [26: 227]. *Anâ keldĭ baar yaz Tereklernĭñ tübĭn kaz* [27: 102]. *Су буенда зиреклек, Тирә-ягы тирәклек* [20: 327]. Татар халык иҗаты әсәрләрендә *тирәкле, тирәклек, тирәксез* дериватлары да очрый: *Су буйлары тирәкле, Без белмибез кирәкне; Су буенда тал-тирәк, Тирәксез җирләр сирәк* [20: 50; 366].

*Dal 'тал'* атамасы добруҗататар һәм татар телләрендә «агач һәм нечкә ботак, нәзек озын сабак» мәгънәсендә кулланыла: *Üy aldında dalımız Yoktır artık malıbız; Daldan dalga cĭp kerdĭm Collarıña gül serdĭm; Armut dalında pĭşer Bek pĭşse cerge tüşer* [27: 158; 121; 104]. *Алмагачның алына, Былбыл кунган талына; Сандугачлар басып сайрый Талның ботакларына* [20: 224; 267]. Талның сыгылмалы озын нечкә тармагы *чыбык* сүзе белән бирелгән очраклар да бар: *Bĭr dal şıbıgından bĭr cay yasay* --- [26: 197] һәм *Сикереп төштем бакчага, Тал чыбыгы алмага* [20: 272].

Кайбер атамаларда мәгънә күчеше күзәтелә. Добруҗататар телендәге *şırpı 'шырпы'* лексемасының дериваты *şırpılık 'шырпылык'* сүзе (kurumuş dal – корыган тал) [29: 244] татар телендә «корыган чыбык-чабыклар, ботак-санаклар»ны аңлата: *Colda, anaw şırpılıkka yetĭşkende, albaştı gene de dĭnlenmege otıra* [26: 197].

Фитонимнарда семантика киңәю очраклары бу лексема белән генә чикләнми. Үсемлекнең анатомиясе, физиологиясе белән бәйле атамалардан *aşlama 'ашлама'* сүзе кызыклы. Татар телендә *ашлама* лексемасы «Үсемлекләрне тукландыру һәм иген уңышын күтәрү максатыннан туфракка кертелә торган органик яисә минераль матдәләр; черемә (тирес, компост, минераль тозлар)» мәгънәсендә теркәлгән [16: 298]. Этимологик сүзлектә дә «ашлама "удобрение" > мар. ашлама id. ~ төр. *aşılama* һ. б. – иске ашла-у < *ашыла*-у "файдалы өстәмә бирү, ялгау, өстән беркетү" сүзеннән. К. ашы» дип бирелә [3:

118]. Добруҗататар фольклор текстларында *aşlama* үзе «үсемлек, үсенте» буларак кулланылган: *Bakşelerde aşlama Aşlamanı taşlama* [27: 109]. *Үсенте, үренте* сүзенең синонимы булган *fidan* төшенчәсе дә очрый: *Biday egemes boldım Fidan tegemez boldım* [27: 116]. «*Филис* һәм *фидан* сүзләре «бәбәк, үсенте» мәгънәсендә бары тик кырымтатар һәм төрек телләрендә генә теркәлгән һәм бу кырымтатар теленең көньяк-көнбатыш яки угыз телләре төркеме (беренче чиратта, төрек теле) белән якын бәйләнешен чагылдыра» [9: 9]. Кырымтатар телендә *aşlama* сүзенең дә төп мәгънәсе – үсенте, үренте. Икенче мәгънәсе – kübre (матдә, мәсәлән, минераль ашлама – maden kübreler).

«Тамырлану, тамыр җибәреп үсә башлау» мәгънәсе *aşlamak* фигыле белән белдерелә: *Suw boyında aşlanır süwüt terek, Curtunda yaşap ölgen dünyada sirek.* [27: 52]. *Җилбер-җилбер җил искәндә Яшь үлән тамырлана; Алларым тамырлана, Гөлләрем тамырлана* [20: 162; 220]. Әлеге сүз «бөреләр ачылу – үсемлекләр яфрак яру, чәчәк ату» мәгънәсендә дә кулланыла: *Gül tereknĭ aşlama Tüşünmiy ĭş başlama* [27: 126].

Татар теленә фарсыдан кергән *мивә* төшенчәсенең кулланышы хәзерге татар әдәби телендә пассивлашкан. Актив кулланышта – *җимеш* атамасы. Фольклор әсәрләрендә дә *җимеш* сүзе кулланылган: *Чынаягым чын имеш*, *Эче тулы чын җимеш*; *Аргы якта бер җимеш, Бирге якта бер җимеш* [20: 331; 228]. Добруҗататар фольклор текстларында да *җимеш* сүзе күп очрый: *Cawın cawsın koraga Cemĭş, şeşek, soganga* [27: 26]. *Bĭr kün o cemĭş tolı findıknıň teregĭne raslay* [26: 245]. *Чәчәк бөресе*н белдергән *гонҗә* атамасы – татар телендә архаизм. Добруҗататар телендә дә *bürĭ* төшенчәсе кулланышта: *Üy aldında gül terek Baar kelse bürlensĭn* [27: 158]. Шул вакытта хәзерге кырымтатар телендә *yemiş* сүзе *meyva* сүзенең синонимы буларак кына кулланыла. Доминанта булып *meyva* атамасы санала. Ә *gönce* сүзе бүгенге көндә дә киң кулланылышта.

Добруҗататар теленең территориаль аерымлануы белән бәррәттән аңа төрек теленең тәэсире дә зур. Төрле сәбәпләр (экстралингвистик факторлар, урбанизация, мәктәптә добруҗататар теле укытылмау, төрек халкы белән янәшә яшәү, язмача беркетелгән әдәби норма булмау һ. б.) аркасында бу күренеш соңгы елларда бигрәк тә көчәя. Борынгы лексика акрынлап төрек эквивалентлары белән алышына бара. Ф.Ф. Гаффарова *орлык* лексемасына чагыштырма-тарихи, структур-семантик анализ ясаган мәкаләсендә «Төрки халыклар шактый якын, тыгыз бәйләнеш саклаган чорда ясалган *орлык* атамасы барлык төрки телләрдә дә тигез таралмаган. Сүзнең бу формасы азәрбайҗан (*тохум*), казах (*тукым*), төрекмән (*тохум*), гагауз (*тоом*/ *тоум*), төрек (*tohym*) телләрендә кулланылу төрки халыкларның территориаль аерымлана башлаган булуын билгели», дип нәтиҗә ясый [5: 73]. Хәзерге кырымтатар әдәби телендә *urluk* орлык сүзе актив кулланылышта йөри. Шул ук вакытта *tuhum* атамасы да күп очрый. Добруҗататар телендә исә киресенчә: *tuhum* сүзе активлашкан, *urluk*

пассивлашкан (сүзлекләрдә искергән сүз пометасы белән бирелгән): *Şölge urluk şaşıdı Cez sandıgıň taşıldı* [27: 154].

Халык авыз иҗаты әсәрләрендәге *vişne ‘чия’* атамасы гомумславян сүзе «*visъn’a*» булып санала, ул добруҗататар теленә төрек теле аша кергән: *Bĭr dalda ekĭ vişne Akız peşĭme tüşme* [27: 114]. Шулай ук *kiraz ‘төчечия’, portaqal ‘әфлисун’* сүзләре дә төрек теле аша алынган: *Bĭr dalda ekĭ kiraz Bĭrĭ al, bĭrĭ biyaz; Biyas, yanagı biyas Dudakları al kiraz; Portaqalnıň sarısı Yerge tüştü yarısı; Portakalnı oyarlar Bĭz nĭşlesek tuyarlar* [27: 145; 114; 115]. Төрек, кырымтатар телләрендә кулланылган *kiraz ‘төчечия’* атамасы коман телендә, *portaqal ‘әфлисун’* сүзе грек, болгар телләрендә дә актив. Гарәп телендә *portaqal ‘әфлисун’* بُرْتُقَالَةٌ *‘буртуķāлат*$^{\text{ун}}$*’* буларак билгеле. Кырымтатар телендә *чия* сүзе *очкынны* аңлата. Бер үк вакытта *kiraz ‘төчечия’нең* синонимы да: *Кырым --- шефтали тереги, эрик тереги, чия / кираз тереги --- белән дан тота* [1: 17].

Анализ добруҗататар авыз иҗаты текстларындагы фитонимнарның хәзерге татар телендә тулы һәм өлешчә параллельләре булуны, шулай ук бер атама урынына икенчесе белән аталуын күрсәтә. Тулы параллель атамаларның күпчелекне тәшкил итүе үсемлек исемнәренең һәм мәгънә, һәм фонетик төзелеш ягыннан гаять тотрыклы, шулай ук бик борынгы булуын раслый. Кайбер сүзләрнең, шактый зур үзгәреш кичерү сәбәпле, беренчел яңгырашы онытылган, алар архаизмга әйләнгән. Бер үк вакытта атамаларның семантик кыры да киңәйгән.

**Әдәбият**

1. *Аджимамбетова Г.Ш., Сныга У.А.* Семантические группы растений в крымскотатарском и русском языках // Научный вестник Крыма. 2021. № 12. С. 15–18.

2. *Ахметова Э.Р.* Названия овощей и фруктов в татарском языке: дис. ... канд. филол. наук: 10.02.02. Казань, 2012. 245 с.: ил.

3. *Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: 2 томда. 1 т. (А–Л). Казан: Мәгариф-Вакыт, 2015. 543 б.

4. *Гаффарова Ф.Ф.* Татар телендә җир эшкәртү лексикасы. Казан: Матбугат йорты, 2000. 176 б.

5. *Гаффарова Ф.Ф.* Орлык атамасына чагыштырма-тарихи, структур-семантик анализ // Жизнь, посвященная тюркологии. Казань: ТГГПУ, 2011. С. 71–74.

6. *Гусейнов Г.А.* К этно- и политогенезу крымских татар и кумыков в историческом контексте их древних и средневековых взаимоотношений // Крымское историческое обозрение. 2014. № 2. С. 23–38.

7. *Джемиль Тахсин.* Татары Добруджи и Буджака // Золотоордынское обозрение. 2013. № 1. С. 164–176.

8. *Меджитова Э.Н.* Методы сбора материала и исследования крымскотатарских диалектов. Симферополь // Научный вестник Крыма. 2018. № 3 (14). С. 15–18.

9. *Меметов А.М.* Диалектные различия в названиях деревьев, кустарников и частей растений в крымскотатарском языке // Научный вестник Крыма. 2017. № 6 (11). С. 1–10.

10. Милли-мәдәни мирасыбыз: Әстерхан татарлары. Казан, 2017. 420 б.

11. Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка. Казань: Фикер, 1998. 130 с.

12. *Саберова Г.Г.* Названия растений в татарском литературном языке. Казань, 1996. 130 с.

13. *Сабитова И.И.* Соматизмы в сказках татар Добруджа и их параллели в татарском языке // Ученые записки крымского инженерно-педагогического университета. Серия: Филология. История. № 3–4. Симферополь: РИО КИПУ имени Февзи Якубова, 2019. С. 26–30.

14. *Сабитова И.И.* Румын татарлары авыз иҗатында сомокомпонентлы паремия һәм фразеологизмнар // Фәнни Татарстан. 2023. № 1 (37). Б. 15–23.

15. *Тагирова Ф.И., Сабитова И.И.* Некоторые лексико-семантические особенности языка добруджанских татар в сравнении с татарским языком (на примере фольклорных текстов) // Теория языка и межкультурная коммуникация. 2024. № 1 (52). URL: https://tl-ic.kursksu.ru/#new-number (дата обращения: 22.12.2025).

16. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. I т.: А–В / [Р.Р. Абдуллина], А.М. Сәгыйтова, Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова, О.Н. Галимова, А.Ф. Гайнетдинова, Г.Д. Фәтхетдинова, Ф.И. Таһирова, И.И. Сабитова, Э.И. Сафина, Ф.М. Газизова. Казан: ТӘһСИ, 2015. 712 б.

17. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. V т.: С–Т / Э.И. Сафина, О.Н. Галимова, Г.Г. Саберова, Р.Т. Сәфәров, А.Ф. Гайнетдинова, Ю.Ф. Борһанова, Ф.И. Таһирова, Ф.Ф. Гаффарова, А.Ә. Тимерханов, Р.Р. Абдуллина. Казан: ТӘҺСИ, 2019. 908 б.

18. Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

19. *Тулегенова Д.М.* Фитонимы в тюркологии // Бюллетень науки и практики. 2021. Т. 7. № 5. С. 595–599. URL: https://doi.org/10.33619/2414–2948/66/67 (дата обращения: 22.12.2025).

20. Татар халык иҗаты. Кыска җырлар (дүртьюллыклар). Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 391 б.

21. Татар эпосы: дастаннар. Казан: Раннур, 2004. 639 б.

22. *Усеинов Т.Б.* Этнокультурные стереотипы степных крымских татар и татар Добруджи на основе пословиц рубежа XIX–XX вв. // Филология: научные исследования. 2020. № 1. DOI: 10.7256/2454-0749.2020.1.31971. URL: https://nbpublish.com/library_read_article.php?id=31971 (дата обращения: 22.12.2025).

23. *Фиргалиева Ч.И.* Лексика садоводства в современном татарском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань. 2007. 20 с.

24. *Хайрутдинова Т.Х.* Народные названия растений в татарском языке. Казань: Фикер, 2004. 224 с.

25. *Хәйретдинова Т.Х.* Табигать концепты: үсемлекләр дөньясы. Казан: ТӘһСИ, 2017. 384 б.

26. Ayuw kulak batır: Dobruca Tatar Masalları. Ekinci kitap / Toplagan, kaytabaştan anlatkan hem ezerlegenler: Nedret Mahmut, Enver Mahmut. Bucureşti: Kriterion kitap üyi, 1991. 252 s.

27. Boztorgay. Folklor toplamı. Ekinci basılış. Eleştirgen, tamamlagan, tertiplegen, tüzetken: Ahmet-Naci Cafer Ali. Bukreş: Kriterion kitap üyi, 1996. 411 s.

28. *Cemil Tahsin*. Tanarii: relatii cu otomani şi romani. Cluj Napoca: Presa Universitara Clujena, 2021. 430 s.

29. Dobruca kırımtatar ağzı sözlüğü. T. 1. A–D. Köstence, 2011. 550 b.

***Сабитова Илһамия Исламетдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

***Сабитова Ильгамия Исламутдиновна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник*
*отдела лексикографии Института языка, литературы и искусства*
*имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*sabitova_1965@mail.ru*